Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы 9-31 номерлы карары

**Казан шәһәре Думасының**
**закон чыгару инициативасы турында**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы белән билгеләнгән закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашырып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына «“Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында”гы Татарстан Республикасы законының 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы законы проектын (кушымта) кертергә.

2. Теркәлгән материаллар белән закон проектын һәм әлеге карарны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә юлларга.

3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгының беренче урынбасарына, закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларында һәм утырышында карап тикшергәндә, аны тәкъдим итүне йөкләргә.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы
9-31 номерлы карарына
кушымта

Проект
Казан шәһәре Думасы
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында»гы Татарстан Республикасы законының 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында»гы Татарстан Республикасы законына (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2023, №96 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны «шәһәр округларының» сүзләреннән соң «, Казан шәһәреннән тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

2) 2 статьяның 3 өлешендәге беренче абзацны «шәһәр округларының» сүзләреннән соң «, Казан шәһәреннән тыш,» сүзләре белән тулыландырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**